КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 26 октябрь г.Казань № 957

«Бәллүр каләм» – «Хрустальное перо» журналистика һәм массмедиа өлкәсендә Республика конкурсы турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

«Бәллүр каләм» – «Хрустальное перо» журналистика һәм массмедиа өлкәсендә Республика конкурсы турында нигезләмә;

«Бәллүр каләм» – «Хрустальное перо» журналистика һәм массмедиа өлкәсендә Республика конкурсы уздыру буенча конкурс комиссиясе составы.

2. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына «Бәллүр каләм» – «Хрустальное перо» журналистика һәм массмедиа өлкәсендә Республика конкурсын әлеге карарга терәлгән Нигезләмә нигезендә үткәрүне тәэмин итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 26 октябрь, 957 нче карары белән расланды

«Бәллүр каләм» – «Хрустальное перо» журналистика һәм массмедиа өлкәсендә Республика конкурсы турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Бәллүр каләм» – «Хрустальное перо» журналистика һәм массмедиа өлкәсендә Республика конкурсы (алга таба – конкурс) оештыручылар – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – конкурсны оештыручы) һәм «Иҗади берлек – Татарстан Республикасы журналистлар берлеге» төбәк иҗтимагый оешмасы (алга таба – Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге).

1.2. Конкурсны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны финанслау конкурсны оештыручыга тиешле финанс елына конкурсны үткәрү өчен Татарстан Республикасы бюджетында каралган акчалар хисабына гамәлгә ашырыла.

## II. Конкурсның максаты һәм бурычы

2.1. Конкурсның максаты – журналистларның һөнәри үсешенә ярдәм итү, аудиториянең журналист сүзенә ышанычын ныгыту, Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларын (алга таба – ММЧ) үстерү.

2.2. Бәйгенең максаты – календарь ел дәвамында медия өлкәсен үстерүгә йогынты ясаган журналистларны һәм ММЧ редакцияләрен ачыклау һәм бүләкләү.

## III. Конкурста катнашучылар һәм гариза бирүчеләр

Конкурста массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре, аерым журналистлар, журналистлар коллективлары катнаша ала.

Конкурста катнашу өчен гариза бирүчеләр – әлеге Нигезләмәнең 5.6 һәм 5.8 пунктлары нигезендә документларны биргән массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре, аерым журналистлар, журналистлар (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр).

Конкурста катнашучылар булып, конкурс эшләре әлеге Нигезләмәнең 6.1 – 6.3 пунктлары нигезендә конкурста катнашырга рөхсәт ителгән гариза бирүчеләр (алга таба – катнашучылар) тора.

## IV. Конкурсның приз фонды һәм номинацияләре

4.1. Конкурс номинацияләре буенча гомуми акчалата бүләк фонды 440,0 мең сум тәшкил итә.

4.2. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

«Эшкә тугрылык өчен» – Татарстан Республикасы журналистикасын үстерүгә һәм журналистлык җәмгыятен ныгытуга өлеш керткән атказанган медиа өлкәсе хезмәткәрләренә, шулай ук матбугат, радио, телевидение, нәшрият-полиграфия эшчәнлеге ветераннарына 80,0 мең сум күләмендә бер премия тапшырыла;

«Елның иң яхшы редакциясе» – Татарстан Республикасының республика, шәһәр һәм район массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләренә 40,0 мең сум күләмендә ике премия тапшырыла;

«Елның иң яхшы журналисты» – Татарстан Республикасының республика, шәһәр һәм район массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларына 40,0 мең сум күләмендә ике премия тапшырыла;

«Объектив аша караш» – Татарстан Республикасының республика, шәһәр һәм район массакүләм мәгълүмат чаралары фотожурналистларына һәм телеоператорларына 40,0 мең сум күләмендә ике премия тапшырыла;

«Туган тел» – татар телендә Татарстан Республикасыннан читтә чыгучы массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләренә һәм журналистларына 40,0 мең сум күләмендә бер премия тапшырыла;

«Татарстан Республикасында милли проектларны яктырту буенча иң яхшы ММЧ редакциясе» – Татарстан Республикасының республика, шәһәр һәм район массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләренә 40,0 мең сум күләмендә ике премия тапшырыла.

4.3. Конкурсны оештыручы Татарстан Республикасында республика, федераль яки халыкара масштабтагы әһәмиятле вакыйгалар үткәрүгә бәйле махсус номинацияләрне билгеләү турында карар кабул итә. Махсус номинациядә җиңүчегә кыйммәтле бүләк тапшырыла, аның бәясе, әлеге Нигезләмәнең 1.2 пункты нигезендә, конкурсны үткәрүгә бүлеп бирелгән акчалар чикләрендә, конкурсны оештыручы тарафыннан билгеләнә.

4.4. Әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктында күрсәтелгән премияләрнең күләме әлеге Нигезләмәнең 7.4 һәм 7.5 пунктларында каралган очракларда һәм тәртиптә арта.

4.5. Конкурсның приз фондын акчалата бүлү, конкурста җиңүчеләргә конкурста катнашу өчен гаризада күрсәтелгән кредит оешмасындагы счетларга премияләрне күчерү (алга таба – гариза), махсус номинациядә җиңүчегә кыйммәтле призны тапшыру конкурс комиссиясе карары һәм әлеге Нигезләмә нигезендә, календарь көннәрендә исәпләнгән 30 көнлек срокта конкурс комиссиясе утырышының йомгаклау беркетмәсенә кул куелган көннән башкарыла.

## V. Конкурсны үткәрү шартлары

5.1. Конкурсны оештыручы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының https://www.tatmedia.tatarstan.ru адресы буенча рәсми сайтында

«Яңалыклар», «Конкурслар һәм проектлар» бүлекләрендә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://www.sj-rt.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге сайтында конкурс үткәрү турында мәгълүмат урнаштырылганнан соң 80 көннән дә соңга калмыйча конкурсны үткәрә. Конкурсны үткәрү турындагы мәгълүматта махсус номинацияләр, конкурска гаризалар кабул итү вакыты һәм тәмамлану вакыты, конкурс эшләре икенче турга узган катнашучыларның исемлекләрен бастырып чыгару датасы күрсәтелә.

Әлеге мәгълүмат конкурска гаризалар кабул итү тәмамланганчы 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

5.2. Әгәр конкурска бер гариза бирелсә яки бер генә гариза да бирелмәсә, конкурс тормышка ашмаган дип таныла.

5.3. Финанслау булмаган яисә җиңелмәс көч шартлары барлыкка килүгә документлар белән расланган очракта, конкурсны оештыручы конкурс эшләрен тапшыру өчен билгеләнгән срокның беренче яртысы эчендә конкурсны юкка чыгару хокукын үзендә калдыра.

5.4. Конкурска Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берсендә конкурс игълан ителгән көнгә кадәр бер ел эчендә иҗат ителгән конкурс эшләре тәкъдим ителә. Россия халыклары телләрендә эшләр тәкъдим ителгән очракта, материаллар рус теленә тәрҗемә белән һәм гариза бирүченең имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән расланган тәрҗемә белән тулыландырыла.

Өченче затларның авторлык хокукларын үтәмәгән өчен закон нигезендә конкурс эшләрен тәкъдим иткән мөрәҗәгать итүчеләр һәм катнашучылар җавап тота.

5.5. Конкурска эшләрнең түбәндәге төрләре кабул ителә:

MP4 форматында һәм (яки) йөкләп алу өчен актив сылтама күрсәтеп CD- яки DVD - дискта һәм (яки) хәтер флеш-картасында бирелгән, дәвамлылыгы 15 секундтан да ким булмаган телевизион эшләр (программалар, махсус репортажлар, телесюжетлар цикллары һәм башка телевизион эшләр);

җитәкче имзасы һәм юридик зат мөһере (булганда) белән яисә физик затлар өчен автор имзасы белән таныкланган, кимендә 500 билгесе булган, оригиналында, ксерокопияләрендә һәм (яки) сканерланган вариантта бирелгән басма ММЧда (публикацияләр серияләре, махсус чыгарылышлар), газеталарда (журналларда, альманахларда) һәм башка басма ММЧда публикацияләр ;

бастырылган рәвештә һәм (яки) CD- яки DVD - дискта һәм (яки) хәтер флеш-картасында йөкләп алу өчен актив сылтама күрсәтеп бирелгән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге басмалар;

MP4 форматында һәм (яки) йөкләп алу өчен актив сылтама күрсәтеп CD- яки DVD - дискта һәм (яки) хәтер флеш-картасында бирелгән, дәвамлылыгы 15 секундтан да ким булмаган радиосюжетлар (программалар, махсус репортажлар, радиосюжетлар цикллары).

5.6. Конкурска тәкъдим ителгән конкурс эшләре рецензияләнми.

5.7. Гариза үз эченә түбәндәге документларны ала:

а) әлеге Нигезләмәнең 5.4 һәм 5.5 пунктлары нигезендә конкурс эше;

б) конкурсны оештыручы тарафыннан расланган форма буенча конкурста катнашу өчен анкета (оригиналы яисә сканерланган PDF форматындагы варианты);

в) юридик затлар сыйфатында теркәлгән ММЧ редакцияләре өчен:

салым органында юридик затны исәпкә кую турында таныклык (салым түләүченең идентификация номеры) (күчермә);

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык (төп дәүләт регистрация номеры), 2017 елның 1 гыйнварыннан соң теркәлгән юридик затлар өчен– юридик затларның бердәм дәүләт реестры язмалары бите (күчермә);

юридик зат җитәкчесен вазыйфага билгеләү турында боерык (күчермә);

оештыру документлары (күчермәләр);

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (конкурска документлар тапшырган көнгә кадәр алты айдан да соңга калмыйча бирелгән);

ММЧ теркәү турында таныклык (күчермәсе) – ММЧ өчен;

г) аерым журналистлар, журналист коллективлары өчен:

шәхесне раслаучы документ (күчермә);

конкурсны оештыручы раслаган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртү, тапшыру һәм таратуга ризалык;

д) юридик зат оештырмыйча гына ММЧ редакцияләре өчен:

ММЧ теркәү турында таныклык күчермәсе;

«Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-I номерлы Россия Федерациясе Законының 20 статьясы нигезендә ММЧ редакциясе Уставының яисә аныалмаштыручы шартнамәнең күчермәсе, әгәр массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясе 10 кешедән ким булса;

е) журналистлар коллективлары, массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре өчен – конкурс эшенә призлы урын бирелгән очракта, акчаны процент ягыннан бүлү турында килешү.

Әлеге пунктның «б» – «е» пунктчаларында күрсәтелгән документлар кәгазьдә тапшырыла (җитәкченең имзасы һәм оешма мөһере (булганда) белән таныклана) яки электрон рәвештә PDF форматындагы күчерелгән вариантта тапшырыла.

5.8. Гаризалар 420080, Казан ш., Декабристлар ур., 179 йорт (өченче подъезд) адресы буенча «Татарстан Республикасы журналистика һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә «Бәллүр каләм – «Хрустальное перо» республика конкурсына» дигән тамга белән кулдан кулга яки почта аша кабул ителә. Белешмәләр өчен телефоннар: 8(843) 555-85-11, 555-76-03.

5.9. Гаризалар конкурсны оештыручы тарафыннан гариза бирүчедән алынган көннән алып бер эш көне эчендә теркәлә.

5.10. Конкурс эшләре конкурска йомгак ясаганнан соң өч ел дәвамында саклана.

5.11. Конкурста катнашу белән бәйле чыгымнар (почта, командировка һәм башка) мөрәҗәгать итүчеләр һәм катнашучылар тарафыннан мөстәкыйль рәвештә түләнә.

## VI. Конкурс эшләрен конкурста катнашуга кертү критерийлары

6.1. Конкурсны оештыручы гаризаны теркәгәннән соң өч эш көне эчендә әлеге Нигезләмә белән расланган таләпләргә туры килү-килмәүгә конкурс эшләрен бәяләү нәтиҗәләре буенча конкурста катнашуга рөхсәт яки рөхсәт бирүдән баш тарту

турында карар кабул итә.

Конкурсны оештыручы, түбәндәге очракларда гариза бирүченең конкурста катнашуга рөхсәтеннән баш тарту турында карар кабул итә:

гариза әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килми;

гаризада дөрес булмаган мәгълүматлар бар;

мөрәҗәгать итүче әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килми.

6.2. Мөрәҗәгать итүчеләргә конкурста катнашуга рөхсәт бирелү һәм конкурста катнашуга рөхсәт бирелмәү турында заказлы хат белән, конкурсны оештыручының җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) кул куйган һәм гаризада күрсәтелгән адрес буенча, конкурста катнашуга рөхсәт бирелү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгәннән соң бер эш көне эчендә тапшырыла.

6.3. Конкурста катнашуга кертелмәгән гаризалар тапшыру өчен билгеләнгән срокта җитешсезлекләрне бетергәннән соң, гариза бирүчеләр конкурска кабат гариза бирә алалар.

## VII. Конкурс комиссиясе

7.1. Конкурс комиссиясе үз эшен түләүсез нигездә башкара.

7.2. Конкурс комиссиясе эше белән рәис җитәкчелек итә. Конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, конкурс комиссиясе рәисе вазыйфалары аның урынбасарына йөкләнә.

7.3. Конкурс комиссиясе рәисе конкурс комиссиясе утырышларын үткәрү урынын, датасын һәм вакытын билгели, конкурс комиссиясе утырышларында рәислек итә һәм конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү мәсьәләләре буенча конкурс комиссиясе секретаренә йөкләмәләр бирә.

7.4. Номинацияләрнең берсе буенча бер гариза бирелгән яки бер генә гариза да бирелмәгән очракта, номинация тормышка ашмаган дип танылa, ә бу номинация буенча премияләргә бүлеп бирелгән акчалар тигез өлешләрдә конкурсны оештыручы тарафыннан башка номинацияләр буенча бүленә.

7.5. Нинди дә булса номинацияләрдә әлеге Нигезләмәнең 8.7 пунктында каралган тиешле күләмдә балл җыйган конкурс эшләре булмаса, конкурс комиссиясе әлеге номинациядә призлы урыннар бирелмәү турында карар кабул итә. Шул ук вакытта әлеге номинациядә премияләргә бүлеп бирелгән акчалар башка номинацияләрдә җиңүчеләр арасында конкурсны оештыручы тарафыннан тигез өлешләрдә бүленә.

7.6. Призлы урын бирелгән бер конкурс эшендә берничә журналист, берничә массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясе дәгъва итсә, номинациянең әлеге призлы урыны өчен күздә тотылган премияләргә бүлеп бирелгән акчалар конкурс комиссиясенә тапшырылган алар арасында төзелгән килешү нигезендә конкурсны оештыручы тарафыннан күрсәтелгән затлар арасында бүленә.

7.7. Конкурс комиссиясе карары нигезендә ике яки берничә катнашучыга призлы урын бирү теләсә кайсы номинациядә баллар тигез булганда гына мөмкин. Шул ук вакытта конкурсны оештыручы әлеге номинациянең әлеге призлы урыны өчен бүлеп бирелгән акчаларны әлеге катнашучыларга тигез өлешләрдә бүлеп бирә.

7.8. Конкурс комиссиясе утырышында мәсьәләләрне хәл иткәндә конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы бер тавышка ия. Тавышны конкурс комиссиясенең бер әгъзасы тарафыннан икенчесенә тапшыру рөхсәт ителми.

7.9. Конкурс комиссиясе үз утырышын аның әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше булганда үткәрә. Конкурс комиссиясе карары конкурс комиссиясе утырышында катнашучыларның күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм беркетмә рәсмиләштерелә.

7.10. Тавышлар тигез булганда конкурс комиссиясе рәисе яисә аны алмаштыручы затның тавышы хәлиткеч булып тора.

7.11. Конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясе составына керми һәм аның утырышларында тавыш бирү хокукыннан башка катнаша.

## VIII. Конкурс эшләрен бәяләү тәртибе һәм критерийлары

8.1. Конкурс ике турда үткәрелә. Катнашучыларның конкурс эшләре гаризалар кабул итү тәмамланганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта конкурс комиссиясе әгъзаларына бәя бирү өчен тапшырыла. Конкурс комиссиясе әгъзалары әлеге Нигезләмәнең 8.2 пунктында билгеләнгән критерийлар нигезендә конкурс эшләрен бәяли.

8.2. Конкурс эшләрен бәяләгәндә түбәндәге критерийлар кулланыла:

1 тур:

конкурс эшләренең конкурс максатларына һәм бурычларына туры килүе (биш баллга кадәр);

материалларның актуальлеге, социаль әһәмияте, иҗтимагый ихтыяҗы (биш баллга кадәр).

2 тур:

аналитиклык, темага үтеп керү тирәнлеге (биш баллга кадәр);

фактологиклык, ышанычлылык, исбатлау базасы (биш баллга кадәр);

бәян итү мөмкинлеге (биш баллга кадәр);

тел чаралары, материалларны бирүнең җанлы ысулларын куллану (биш баллга кадәр);

шәхси иҗади стиль күрсәтү (биш баллга кадәр);

композицион-структур төзелеш, башлау комплексын рәсмиләштерү (басма материаллар өчен), материалларны иллюстратив чаралар, инфографика белән алып бару (биш баллга кадәр).

8.3. Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурсның беренче туры өчен әлеге Нигезләмәнең 8.2 пунктында билгеләнгән критерийлар буенча конкурс эшләрен аларны алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә бәяли.

Икенче турга конкурсның беренче туры өчен әлеге Нигезләмәнең 8.2 пунктында күрсәтелгән критерийлар буенча конкурс эшләре сигездән дә ким булмаган балл җыйган катнашучылар уза.

8.4. Конкурсның беренче турына нәтиҗәләр конкурс комиссиясе утырышында конкурска гаризалар кабул итү тәмамланганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча ясала һәм конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

8.5. Конкурс үткәрү турындагы мәгълүматта күрсәтелгән датадан да соңга

калмыйча, икенче турга үткән катнашучылар исемлеге «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында басылып чыга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының https://www.tatmedia.tatarstan.ru адрес буенча сайтында «Яңалыклар», «Конкурслар һәм проектлар» бүлекләрендә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Журналистлар берлегенең https://www.sj-rt.ru адресы буенча сайтында урнаштырыла.

8.6. Икенче турга узган катнашучыларның конкурс эшләре бәйгенең беренче турына йомгак ясаганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә конкурс комиссиясе әгъзаларына тапшырыла, алар алган көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә әлеге Нигезләмәнең 8.2 пунктында билгеләнгән критерийлар буенча икенче тур өчен бәялиләр.

8.7. Конкурста җиңүчеләр ике тур нәтиҗәләре буенча җыйган конкурс эшләре арасында тавыш бирү юлы белән конкурс комиссиясе тарафыннан ачыклана:

«Эшкә тугрылык өчен», «Елның иң яхшы редакциясе», «Елның иң яхшы журналисты», «Объектив аша караш», «Туган тел», «Татарстан Республикасында милли проектларны яктырту буенча иң яхшы ММЧ редакциясе» номинацияләрендә 30 баллдан да ким булмаган санда;

махсус номинацияләрдә кимендә 25 балл.

8.8. Конкурска йомгак конкурс комиссиясе тарафыннан, гаризалар кабул итү тәмамланганнан соң календарь көннәрдә исәпләнгән 60 көн эчендә ясала һәм конкурс комиссиясе рәисе яки аның урынбасары кул куйган беркетмә белән, конкурс комиссиясе утырышын үткәргәннән соң календарь көннәрдә исәпләнгән өч көн эчендә рәсмиләштерелә.

8.9. Конкурс комиссиясе утырышының йомгаклау беркетмәсе аңа кул куелган көннән алып календарь көннәрдә исәпләнгән өч көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының https://www.tatmedia.tatarstan.ru адрес буенча урнашкан рәсми сайтында «Яңалыклар», «Конкурслар һәм проектлар» бүлекләрендә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Журналистлар берлегенең https://www.sj-rt.ru адресы буенча урнашкан сайтында урнаштырыла.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 26 октябрь, 957 нче
карары белән расланды

«Бәллүр каләм» – «Хрустальное перо» республика конкурсын уздыру буенча
конкурс комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Латышев Александр Николаевич | «Республика Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең баш мөхәррире, конкурс комиссиясе рәисе (килешү буенча) |
| Гыймалетдинов Фирдүс Салих улы | «Бөтенроссия дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе» федераль дәүләт унитар предприятиесенең «Татарстан Республикасы дәүләт телевизион һәм радиотапшырулар компаниясе» филиалы директоры, конкурс комиссиясе рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Насыйбуллина Алсинә Рамил кызы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге баш белгече, конкурс комиссиясе секретаре |

Конкурс комиссиясе әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әхмәтова Эльвира Фәнис кызы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенеңберенче урынбасары |
| Второв Дмитрий Юрьевич | «Бөтенроссия дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе» федераль дәүләт унитар предприятиесенең «Татарстан Республикасы дәүләт телевизион һәм радиотапшырулар компаниясе» филиалы директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Галиев Рамил Якуб улы | «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте филиалы «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы» фотографы (килешү буенча) |
| Галиуллин Рөстәм Госман улы | «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте филиалы «Казан утлары» журналы редакциясе» баш мөхәррире (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Гафиятов Атлас Хәмидулла улы | «Татарстан яшьләре» газетасының баш мөхәррире (килешү буенча) |
| Назаров Станислав Сергеевич | Корреспондент челтәре хезмәтенең Россиядә «Бөтенроссия дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе» федераль дәүләт унитар предприятиесенең корреспондент челтәренең Казан шәһәрендәге корреспондент пункты мөдире (килешү буенча) |
| Сәфәров Данил Наил улы | Matbugat.ru сайты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Фазуллин Илназ Фаис улы | «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте филиалы «Ялкын» журналы редакциясе» баш мөхәррире (килешү буенча) |
| Шәйхиева Гөлназ Фирдинат кызы | Бөтендөнья татар конгрессы республика иҗтимагый фондының мәгълүмат хезмәте һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтәләр буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Шерстнев Сергей Валерьевич | «Телевизион яңалыклар хезмәте» мәгълүмат-телевизион агентлыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте шеф-мөхәррире (килешү буенча) |
| Хәйдәрова Наилә Зөлкәрәм кызы | «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыятенең «Болгар радиосы» башкарма директоры (килешү буенча). |